


Ә.Н. ХУҖИӘХМӘТОВ

# ТӘРБИЯ ТЕОРИЯСЕ ҺӘМ МЕТОДИКАСЫ

## СОЦИАЛЬ ПЕДАГОГИКА



УДК 37.0(075.8)
ББК 74.202 я73
Х80

*Казан (Идел буе) федераль университетының психология һәм мәгариф институты гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә (беркетмә № 2, 26 февраль, 2015 ел).*

**Рецензентлар:**
педагогика фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе **И.Т. Гайсин;**
педагогика фәннәре кандидаты, доцент, Халыкара педагогик хезмәттәшлек академиясе әгъза-корреспонденты **Н.П. Ячина**

*Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.*

**Хуҗиәхмәтов Ә.Н.**
**Х80** **Тәрбия теориясе һәм методикасы. Социаль педагогика:** югары һәм махсус урта уку йортлары өчен лекцияләр курсы / Ә.Н. Хуҗиәхмәтов. – Казан: Казан ун-ты нәшрияты, 2015. – 367 б.

**ISBN 978-5-00019-371-6**

Лекцияләр курсының төп максаты – тулы, бербөтен педагогик процессны, шәхесне һәрьяклап үстерү юнәлешләрен ачып бирү, педагогик технологияләрнең теоретик нигезләрен өйрәнүдә һәм яшь буынга тәрбия бирүне дөрес итеп оештыру юлларын табуда укытучыларга, тәрбиячеләргә булышу. Китапта әлеге фәннең максатлары һәм бурычлары билгеләнә, төп педагогик төшенчәләргә анализ ясала, тәрбия концепцияләренең эчтәлеге һәм теоретик нигезләре бәян ителә.

Мәктәп, лицей, гимназия укытучыларына, югары һәм махсус урта уку йортлары студентларына тәкъдим ителә.

**ISBN 978-5-00019-371-6**

**УДК 37.0(075.8)**
**ББК 74.202 я73**

**© Хуҗиәхмәтов Ә.Н., 2015**
**© Казан университеты нәшрияты, 2015**

## КЕРЕШ

Педагогика — кешегә тәрбия бирү турындагы фән ул. Педагогика *«педагогос»* — *«балалар җитәкчесе»* дигән сүздән алынган. Борынгы Грециядә балаларны мәктәпкә алып бару, алып кайту һәм аларны карау эше тапшырылган кешеләрне педагоглар дип йөрткәннәр. Соңыннан тәрбияче һәм укытучыларны *педагог* дигәннәр. Аларның эше *педагогик эшчәнлек* дип атала башлаган.

Педагогика — тәрбия бирүнең максат һәм бурычлары, эчтәлеге, алымнары һәм аны оештыру турындагы тәгълимат ул. Икенче төрле әйткәндә, үсеп килүче яшь буынны нинди эшләр башкарырга әзерләргә, аларда нинди сыйфатлар булдырырга, аларны нәрсәгә һәм ничек өйрәтергә, ничек тәрбияләргә дигән сорауларга педагогика җавап бирә.

Педагогиканың предметы, җәмгыятьнең махсус функциясе буларак,— кеше тәрбияләү. Башкача әйткәндә, педагогиканың предметы булып тәрбия эшчәнлеге тора.

Кешелек җәмгыяте үсеше тарихында яшь буынны тәрбияләүгә һәркайчан зур игътибар бирелеп килгән. Җәмгыять әле иҗтимагый сыйныфларга бүленмәгән, кеше өстеннән хакимлек итү булмаган чакта, өлкәннәр үз тәҗрибәләрен яшь буынга турыдан-туры эш процессында тапшырганнар. Ул чор тәрбиясендә аңлылыкка караганда стихиялелек көчлерәк булган. Ләкин борынгы җәмгыятьтә үк инде, алга барган саен, тәрбия эше максатчанрак була барган.

Иҗтимагый сыйныфлар килеп чыккач һәм алар арасында көрәш җәелеп киткәч, хаким сыйныфлар тәрбия эшен хезмәт ияләрен изү чарасы итеп тә файдаланганнар. Шуның белән бергә, акрынлап яшь буынны тәрбияләү тәҗрибәсе туплана барган, махсус тәрбия йортлары барлыкка килгән, тәрбия һәм укыту эше белән аерым шөгыльләнүче кешеләр килеп чыккан, булган тәҗрибәнең мәгънәсенә төшенү, аны гомумиләштерү зарурлыгы туган. Шулай итеп, кешелек җәмгыяте ихтыяҗларыннан мәктәп барлыкка килә, ә аннары үсеп килүче яшь буынны тәрбияләү һәм аңа белем бирү турындагы фән — педагогика килеп чыга. Педагогика тәрбия бирүнең максат һәм бурычлары, аның эчтәлеге, методлары һәм оештырылуы турындагы тәгълиматны эченә ала. Икенче төрле итеп әйткәндә,